Чистай муниципаль районы
Данауровка авыл җирлеге Советы
карары

№28/1 2017 елның 17 феврале

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
«Данауровка авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге Уставына үзгәрешләр
кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Данауровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 84 – 86 статьялары нигезендә, Данауровка авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Данауровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяның 1 пунктын 14 пунктчасы белән тулыландырырга:

«14) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру.»;

1.2. 9 статьяны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Җирлектә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче вазыйфаи затларга пенсиягә чыгу сәбәпле бер мәртәбә бүләкләү гарантияләнә. Бер тапкыр бүләкләүнең шартлары, күләме һәм тәртибе Җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.»;

1.3. 19 статьяның 3 пунктындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Җирлек Уставы проекты, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, Җирлек Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яки законнары нигезләмәләрен төгәл яңарту рәвешендә үзгәрешләр кертелү очракларыннан тыш, әлеге Уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында;»;

1.4. 39 статьяның 3 пунктында «Хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5. 4 пунктның 43 статьясында «йә вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату» сүзләрен «, Җирлек башлыгына вәкаләтләрне вакытыннан алда

туктату йә суд карары буенча процессуаль көчләү чараларын кулга алу яисә вазыйфадан вакытлыча читләштерү чараларын куллану» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 47 статьяның 2 пунктын түбәндәге абзац белән тулыландырырга:

«- «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чаралар гамәлгә ашыра.»;

1.7. 55 статьяны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирлектә муниципаль вазыйфаларны биләүче вазыйфаи затларга, күрсәтелгән затларның вәкаләтләрен туктату очракларыннан тыш, пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләкләүне түләү гарантияләнә, моннан тыш, 35 статьяның 16 өлешендәге 16 абзацында, 6 өлешнең 2.1, 3, 6 - 9 пунктларында, 36 статьяның 6.1 өлешендә, 7.1, пунктларда, 36 статьяның «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 10 өлешнең 10.1 өлеше, 73 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләре. Бер тапкыр бүләкләүнең шартлары, күләме һәм тәртибе җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.»;

1.8. 84 статьяда:

3 пунктның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Җирлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук Җирлек Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яки законнары нигезләмәләрен төгәл яңарту рәвешендә үзгәрешләр кертелгән очракта, әлеге норматив хокукый актларга туры китерү турында гражданнарның фикер алышу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) кирәк түгел.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Җирлек Уставы проекты буенча, Җирлек Советы утырышында әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турындагы карар карарлары буенча Җирлек Советы утырышында әлеге Уставка туры китереп ачык тыңлаулар үткәрелә, моннан тыш, Җирлек Уставын шушы норматив хокукый актларга туры китерү максатларында Җирлек Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яки законнары нигезләмәләрен төгәл яңарту рәвешендә үзгәрешләр кертелә.».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыелган урыннарда, стендларда һәм бюллетеньнәрдә элү юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Данауровка авыл җирлеге
башлыгы В.К. Сәдретдинова